Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Олы Елга авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

16 ноябрь 2023 ел № 8

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Елга авыл җирлеге составына керүче Олы Елга авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең Олы Елга авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан, беренче торкем инвалидлардан мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан гайре), 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- авыл җирлегенең Олы Елга торак пунктында урам утларына энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру һәм алыштыруга;
- Олы Елга торак пунктында урамнарның юл йөрү өлешен кышын карап торуга (кардан чистартуга);
- Олы Елга авылының Яңа-2, Мәктәп, Совет, Яшьләр урамнарында юлларны төзекләндерүгә;
- Олы Елга авылына янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыруга;
- Олы Елга авылындагы Сабантуй мәйданы сәхнәсен ремонтлауга;
- Олы Елга авылы зиратын чистартуга.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Елга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Олы Елга авылы, Октябрь урамы, 25 йорт; Казаклар авылы, Үзәк урам, 9 йорт; Сорочьи Горы авылы, Үзәк урам,16а йорт; Кама поселогы, Курортная-2 урамы, 23 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Елга авыл җирлеге башлыгы: Мингалеев И.Н.

